| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘРКӘТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** | | **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЧЕРЕМШАНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** |
| **423106, БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ, ЛЕНИН УРАМЫ, ЙОРТ 76 “а”** | **тел.+7(84396) 2-64 -66 тел./факс +7(84396) 2-64-66** | **423106, СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ, УЛИЦА ЛЕНИНА, ДОМ 76 «а»** |

**№150** **10.09.2020 ел**

# КАРАР

«Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советы карар итте:

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге башлыгы Гайнанова Г.Х.

Чирмешән муниципаль
районы Бәркәтә авыл җирлеге
Советының карары белән
расланган
_____________№____

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба – Авыл) һәм Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба – Район) арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзүнең әлеге тәртибе 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон (алга таба - «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль закон) нигезендә эшләнде.

2. Авылның җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Авыл бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Район җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзергә хокуклы.

Шул ук вакытта Район җирле үзидарә органнары «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Район җирле үзидарә органнарына Авылның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә Авыл

территориясендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыруны Авылның һәм Районның җирле үзидарә органнары башлап җибәрә ала.

5. Авыл муниципаль берәмлеге башкарма комитеты үз инициативасы белән яисә Районның җирле үзидарә органнары инициативасын карап, аны алганнан соң 30 көн эчендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында Авыл Советы карары проектын әзерли.

6. Авыл муниципаль берәмлеге башкарма комитеты Авыл Советына норматив хокукый актлар кертүндә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Авыл Советы карары проектын кертә.

7. Авыл Советы Район җирле үзидарә органнарына Авылның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында карарны кабул итә һәм кабул ителгән карарны Район җирле үзидарә органнарына карауга җибәрә.

8. Район Советы тарафыннан Авыл Советы карарын уңай карау нәтиҗәсендә Авыл җирле үзидарә органнары һәм Район җирле үзидарә органнары арасында килешү төзелә.

Күрсәтелгән килешү билгеле бер вакытка төзелергә тиеш, аның гамәлдә булуын туктату, шул исәптән вакытыннан алда нигезләрен һәм тәртибен билгеләүче нигезләмәләрне, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган әлеге өлештә күрсәтелгән бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү тәртибен тупларга, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

Килешү проектын эшләү өчен һәр яктан тигез санда вәкилләрне кертеп, эшче төркем төзелергә мөмкин. Эшче төркем үз эше нәтиҗәләре буенча килешү якларның мәнфәгатьләрен максималь рәвештә исәпкә алучы килешү проектын әзерли.

9. Әгәр Авыл Советы, инициативаны җибәрүче Район җирле үзидарә органнарына Авылның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы карар проектын кире какса, алар башлап җибәргән сорауны карау нәтиҗәләре турында хат җибәрелә.

10. Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

Бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган очракта алар Авыл бюджетына ун көнлек срокта кире кайтарылырга тиеш.

Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында, бюджет законнары нигезендә, тапшырылган вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле чаралар каралган район һәм авыл бюджеты турындагы карарларга үзгәрешләр кертелә.

Бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Авыл бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары ай саен тигез өлешләр белән күчерелә, әмма финанс чараларының барлык суммасын бер үк вакытта күчерү мөмкин.

11. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булган очракта, түләүсез сроклы файдалану килешүе нигезендә муниципаль милек тапшырыла.

Түләүсез файдалану килешүе сроклы булып тора һәм Килешү гамәлдә булу срогына төзелә.

12. Күрсәтелгән килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Район җирле үзидарә органнары Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарында каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.

13. Вәкаләтләрен тапшырган авылның җирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра, тапшырылган

финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны сорый.

14. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- Яклар килешүе буенча;

- берьяклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта.

15. Килешүнең гамәлдә булуы срогыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Район җирле үзидарә органы вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди ресурсларны һәм мөлкәтне кире кайтара.

16. Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедураларын үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.